ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29 01 2021 г. № 59

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 73 номерлы карары белән, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына Түбән Кама шәһәре, Кама Аланы ш.т.п. һәм Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләре өлешен тапшыру турында кабул ителгән килешүләрне игътибарга алып, карар бирәм:

1. Әлеге карарга 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә, Түбән Кама муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 2021 елның 1 февраленнән 6 424,98 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2020 елның 31 гыйнварындагы 47 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 29 нчы гыйнвар
59 нчы номерлы карарына
1 нче кушымта

Түбән Кама муниципаль районында 2021 елның 1 февраленнән
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге
бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2.  Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яраклар бирү һәм китерү | 450,0 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка илтү | 496,98 |
| 4. Җирләү (кабер казу (2,20м*1м)  һәм күмү) | 5 478,0 |
| Барлыгы | 6 424,98 |

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 29 нчы гыйнвар
59 нчы номерлы карарына
2 нче кушымта

Түбән Кама муниципаль районында 2021 елның 1 февраленнән
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге
бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Мәетне киендерү (кәфенләү) | 245,0 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яраклар бирү һәм китерү | 450,0 |
| 4. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка илтү | 496,98 |
| 5. Җирләү (кабер казу (2,20м*0,7м) һәм күмү) | 5 233,0 |
| Барлыгы | 6 424,98 |